РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН
**ГЛАВА**
**Большесалтыковского сельского поселения**
***Камско-Устьинского***
**муниципального района**

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
**Кама Тамагы**
**муниципаль районы**
**Олы Салтык авыл жирлеге**

**БАШЛЫГЫ**

ул.х.Такташ, 132, с.Большие Салтыки, 422831
тел. (8437) 35-8-19 факс: (8437) 35-8-19
ИНН 1622001869

Х.Такташ урамы, 132, Олы Салтык авылы., 422831,
тел. (8437) 35-8-19 факс: (84377) 35-8-19
ИНН 1622001869

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**26.08.2020 ел** **№ 19**

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлегенең Олы Мәрәтхуҗа торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлеге Уставының 24.1 статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. 2020 елның 07 сентябрендә 13 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлегенең Олы Мәрәтхуҗа торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

“Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлегенең Олы Мәрәтхуҗа авылында 2020 елдагы гражданнарның үзара салымын хәл итү өчен 90 966 (туксан мең тугыз йөз алтмыш алты) сум күләмендә кабул итү буенча үткәрелгән эш нәтиҗәләре буенча экономияләнгән акчаларны түбәндәге эшләрне эшләргә яңадан җибәрүгә килешәсезме?:”

- зират территориясен төзекләндерү (шул исәптән контейнер мәйданчыгы урнаштыру һәм контейнер сатып алу, зиратка керү юлындагы күперне ремонтлау өчен материаллар сатып алу);
- авыл территориясен төзекләндерү (шул исәптән триммер сатып алу, Гагарин урамы буенча керү юлында киртә);
- юлларны ремонтлау һәм карап тоту.

**«ӘЙЕ»** **«ЮК»**

3. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмати стендларда халыкка җиткерергә:
- ТР, Кама Тамагы районы, Олы Салтык авылы, Свердлов урамы, 126 йорт;
- ТР, Кама Тамагы районы, Мәрәтхуҗа авылы, Ленин урамы, 61 йорт, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә 3(өч) көн эчендә урнаштырырга кирәк.

4. Әлеге карар халыкка игълан ителгән (басылып чыккан) көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлеге башлыгы** **Х.Х. Ибәтов**